2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авылы җирлеге Югары Мактама авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

01 ноябрь 2025 ел №2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлегенең Югары Мактама авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге Югары Мактама авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 550 сум күләмендә үзара салым кертергә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан, 85 яшьтән өлкәннәрдән тыш, I-II төркем инвалидларны искәртеп.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: ягъни су белән тәэмин итү системасын, су башняларын, коеларны һәм су чыганакларыннан су алуны, суны гражданнарга ташуны һәм бирүне тәэмин итүче башка инженерлык коммуникацияләрен төзү һәм ремонтлау эшләре өчен юнәлтергә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 50 нче йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Мактама авыл җирлеге башлыгы Н.Т.Нуриев